**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№6379**
**27.11.2020**

2020-2021 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю урыннары турында

Карны үз вакытында чыгаруны тәэмин итү һәм кар өюне тәртипкә салу максатларында, Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең 190 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. 2020-2021 елларның кышкы чорында вакытлыча кар өю өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1) кадастр номерлары 16:52:100305:74, 16:52:100305:105 һәм 16:52:100305:8 булган җир участокларының үзәгендә урнашкан, мәйданы 3 га булган, формалаштырылмаган участок территориясендә;

2) кадастр номеры 16:52:100101:117, мәйданы 22,75 га булган җир участогы территориясендә.


2. 2020-2021 елларның кышкы чорына вакытлыча кар өю урыннарының урнашу схемасын кушымтада каралганча расларга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы С.Ә. Ситдыйковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 27 ноябрендәге
6379 номерлы карарына
кушымта

2020-2021 елларның кышкы чорына вакытлыча кар өю урыннарының урнашу
схемасы




## Условные обозначения:

1 — Несформированный участок, площадью 3 га, расположенный в центре земельных участков с кадастровыми номерами 16:52:100305:74, 16:52:100305:105 и 16:52:100305:8

2 — Земельный участок с кадастровым номером 16:52:100101:117 площадью 22,75 га

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе
урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе
башлыгы вазыйфаларын бащкаручы А.Ф. Бареева